РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 59** **2019 елның 12 сентябре**

«Иске Чишмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 нче статьясы, Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Иске Чишмә авыл җирлеге Советының 2013 елның 6 мартындагы 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. ОД-1 «күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона» территориаль зонасын файдалануның рөхсәт ителгән төп төрләренә «балалар бакчалары, башка мәктәпкәчә тәрбия объектлары» һәм « - башлангыч һәм урта мәктәпләр» сүзләрен өстәргә (1 нче кушымта);

1.2. шәһәр төзелешен зоналаштыру һәм территорияләрне файдалануның махсус шартлары булган зоналар карталарында территориаль зонаны (16:30:070203:416 кадастр номерлы, 16:30:070202:37 кадастр номерлы җир кишәрлекләре өлешендә) Ж-1 шәхси торак йортлар төзү зонасыннан ОД-1 күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зонага үзгәртергә (2 нче кушымта);

1.3. шәһәр төзелешен зоналаштыру һәм территорияләрне файдалануның махсус шартлары булган зоналар карталарында Иске Чишмә, Ачы авылларындагы санитар-саклау зоналарын һәм СН-1 чыганакларын төшерергә (3 нче кушымта).

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларының матбугат басмаларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы һәм Иске Чишмә авыл җирлегенең рәсми сайтларында бастырып чыгарырга;

4. Әлеге карарны Россия Федерациясе территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында (РФ ТП ФДМС) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

А.Р. Метшин

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2019 елның 12 сентябрендәге
[illegible]9 номерлы карарына
1 нче кушымта

**ОД-1. Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона**

ОД-1 күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зонасы күпфункцияле кулланыштагы административ, эшлекле, иҗтимагый, мәдәни, хезмәт күрсәтүче һәм коммерция файдалану төрләре булган киң спектрлы объектларны формалаштыруның хокукый шартларын тәэмин итү өчен бүлеп бирелгән.

**Күчемсез милекне рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре:**

- административ-хуҗалык, эшлекле, иҗтимагый учреждениеләр һәм оешмалар;
- күпфункцияле эшлекле һәм хезмәт күрсәтүче биналар;
- кунаханәләр;
- балалар бакчалары, башка мәктәпкәчә тәрбия объектлары;
- башлангыч һәм урта мәктәпләр;
- мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре;
- конфессиональ объектлар;
- дини юнәлештәге уку йортлары;
- клублар;
- амбулатор-сырхауханә учреждениеләре;
- даруханәләр;
- фельдшер-акушерлык пунктлары;
- ачык, ябык ваклап сату базарлары;
- кибетләр;
- җәмәгать туклануы предприятиеләре;
- көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары;
- прокат пунктлары;
- җәмәгать бәдрәфләре;
- физкультура-спорт комплексы;
- көймә станцияләре;
- спорт мәктәпләре;
- спорт заллары, рекреация заллары (бассейнлы яки бассейнсыз), бассейннар;
- күпмаксатлы һәм махсуслаштырылган билгеләнештәге клублар;
- спорт мәйданчыклары, теннис кортлары;
- майданнар;
- урта махсус уку йортлары;
- укыту-җитештерү остаханәләре;
- тулай торак;
- элемтә предприятиеләре;
- полиция участок пунктлары, бүлекчәләр;
- янгын депосы;
- маллар тотмый торган ветеринария шифаханәләре.


Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р. Долотказина

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2019 елның 12 сентябрендәге
номерлы карарына
нче кушымта

**СТАРОШЕШМИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

*Карта градостроительного зонирования*

Выкопировка. с.Старошешминск.





Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р. Долотказина

Түбән Кама муниципаль районы
оветының
019 елның 12 сентябрендәге
9 номерлы карарына
нче кушымта


**СТАРОШЕШМИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

***Карта зон с особыми условиями использования территории***

Выкопировка. с.Старошешминск.




Выкопировка. с.Ачи




Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р. Долотказина